

# 23нче мәктәп музее

Школа № 23 Ново-Савиновский р-н г. Казань



**I. Музейның исеме:** Бөек Ватан сугышының 96 нчы укчы дивизиясенә багышланган "Сугышчан дан" музее .

**II. Музейның оешуы** 31. 03. 80 ел.

Төрле елларда музей белән тарих укытучылары җитәкчелек итәләр: Краюшкина Л.В., Гайфутдинова Р.Ф., Овчинникова Н.Г..

**III.**Музей 96 нчы укчы дивизиясенә багышланган . Аның фондында:

сугыш кораллары;
сугышчыларның шәхси киемнәре;
фотолар;
сугыш карталары;
сугышчан листовкалар;
хатлар .

**IV. Бүлекләрнең темалары**




# I кат

- Бөек Ватан сугышы башлану күренешләре;
- 96 нчы укчы дивизия формалашу;
- Дивизиянең Калуга һәм Белоруссиядәге көрәше;
- Гомель һәм Кенингсберг шәһәрләрен азат итү;
- Дивизиянең хәрәкәтләрен сурәтләгән карта.

## Баскыч

## Советлар Союзы геройлары галереясы















# Булатов Фатых Гарипович



- Булатов Фатых Гарипович- татар халкының танылган улы. Ул гади татар крестьян малаеннан Совет Армиясенең генерал-майор дәрәҗәсенә җитә.

  1902 нче елда Татарстанның Азнакай районы Түбән Сукояш авылында туа.

  Октябрь революциясеннән соң авыл Советы эшендә, мәгърифәт,мәдәният өлкәләрендә эшли.

1923 елда ТатЦИКа исемендәге татар-башкорт хәрби мәктәбен тәмамлап тормышын Совет Армиясе белән бәйли.

1927 елдан – партия сафларында. Сугыш башланыр алдыннан Алабугада полк мәктәбе ,аннары батальон белән җитәкчелек итә.

1939 нчы елда Монголиягә китә, көзен Буратиягә җибәрелә.

1941 нче елдан 1945 нче елга хәтле фронтта полк, дивизия белән җитәкчелек итә.

# Әфганстан



Моисеенков Леонид Ананий улы 1939 елның 13 февралендә Брянск өлкәсенең Серпеевка авылында туа. Дубровский районындагы Речица авылында урта мәктәпне тәмамлый. Армиядә хезмәт итә.1957 нче елда Омск шәһәрендә М.В.Фрунзе исемендәге хәрби училищесын тәмамлый.1961-1964 нче елларда Польшада хезмәт итә.1964-1969 нчы елларда КВИАУ да укый. 1975-1982 нче елларда Ерак Көнчыгышта хезмәт итә. 1983-1985 нче елларда Әфганстанда хезмәт итә.1985-1990 нчы елларда- Германиядә.

# Музеебызның экспонатлары









